**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3043**
**14.06.2019**

Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылыкны яклаучы
изге Петр һәм Феврония Муромскийларны
искә алу көнен оештыру һәм үткәрү турында

Башкарма комитетның 2018 елның 1 ноябрендәге 6510 нчы карары белән расланган «2019-2021 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы халыкларының милләтара элемтәләрен һәм дуслыгын ныгыту һәм шәһәр халкының ялын оештыру максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәдәният идарәсенә 2019 елның 8 июлендә «Боровецкий» бульварында Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылыкны яклаучы изге Петр һәм Феврония Муромскийларны искә алу көнен үткәрергә.
2. Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылыкны яклаучы изге Петр һәм Феврония Муромскийларны искә алу көненә әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты составын 1 нче кушымтада каралганча расларга.
3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылыкны яклаучы изге Петр һәм Феврония Муромскийларны искә алу көнен оештыру һәм үткәрү буенча чыгымнарны финанслауга акча бүлеп бирүне 2019 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Мәдәният» 0801 бүлегендә (бүлекчәсендә) каралган акчалар хисабына 30 000 (утыз мең) сум күләмендә, 2 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.
4. Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсенә (Н.Д. Закировка) чара үткәрү урыннарында гражданнар иминлеген һәм җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 14 июнендәге
3043 нче карарына
1 нче кушымта

Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылыкны яклаучы изге Петр һәм Феврония Муромскийларны искә алу көненә әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты
составы

| | | |
|---|---|---|
| | Хәлимов Рамил Мәрван улы | оештыру комитеты рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 1. | Галиуллин Рөстәм Рәфыйк улы | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсенең җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге башлыгы |
| 2. | Закиров Надир Дамир улы | Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе башлыгы (килешенү буенча) |
| 3. | Ишалина Ландыш Риф кызы | Яр Чаллы шәһәренең «Чишмә» халыклар дуслыгы йорты» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесе директоры |
| 4. | Кәрамиев Румил Рәүф улы | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе башлыгы |
| 5. | Мөхәммәтҗанова Римма Равил кызы | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе башлыгы |
| 6. | Сафиуллин Рим Миннур улы | Яр Чаллы шәһәренең «Мәдәният һәм ял паркы» муниципаль унитар предприятиесе директоры |
| 7. | Харисов Винер Хәмит улы | Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы. |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2019 елның 14 июнендәге
3043 нче карарына
2 нче кушымта

Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылыкны яклаучы
изге Петр һәм Феврония Муромскийларны искә алу көнен үткәрү буенча чыгымнар
сметасы

| Т/с | Чыгымнарның исеме | Сумма (сум) | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Сувенир продукциясе сатып алу | 20 000,00 | «Чишмә» халыклар дуслыгы йорты» МАМУ |
| 2. | Полиграфия хезмәтләре:<br>- афишалар, бейджлар әзерләү<br>- дипломнар, рәхмәт хатлары әзерләү | 2 000,00<br>3 000,00 | |
| 3. | Йола җырлары һәм көйләре фонограммасын яздыру | 5 000,00 | |
| барлыгы: | | 30 000,00 | |

Барысы: 30 000 (утыз мең) сум 00 (ноль) тиен.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова